**ГЛАВА НАРМОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

422630,РТ, Лаишевский район, село Нармонка, ул.Молодежная , д.12
8-(84378) -4-62-24
факс: 8-(84378) -4-62-24

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НАРМОНКА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ**

422630, РТ, Лаеш районы, Нармонкаавылы, Яшьләр урамы, 12 А нчейорт
тел: 8-(84378) -4-62-24
факс: 8-(84378) -4-62-24

---

2023 елның 27 октябре 12 номер

# КАРАР

## Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлегенең Караеш торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлеге Уставының 23 статьясы, Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2023 елның 12 ноябрендә 15 сәгать 30 минутка билгеләргә.

1.Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

Муниципаль район Караеш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, балачактан инвалидлардан, көндезге формада укучы студентлардан тыш, 2024 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юллауга сез ризамы?

- Караеш авылында урамнарны яктырту, урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергияне сак тоту яктырткычлары, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

« РИЗА» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында һәм Нармонка авыл җирлегенең рәсми сайтында кабул ителгән көннән алып биш көн эчендә халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Башлык-Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлеге Советы рәисе** **И.Ф. Мөбәрәкшин**